ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октября, з/у1Б,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Октябрь урамы, 1Б йорт,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 6-23-33, факс:6-25-28, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 13** **«03» апрель 2020 ел**

2020 елда "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 маддәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында»гы 2019 елның 22 июнендәге 796 санлы карары нигезендә, Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру тәртибен һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә 1 сентябрьгә кадәр муниципаль берәмлек башкарма комитетына хисап елы өчен, хисап елына кадәрге ел өчен белешмәләр җибәрергә тәкъдим итәргә:

ташламалардан файдаланучы түләүчеләр саны турында;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең һәр салым кереме буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең төшеп калган керемнәр суммасы турында.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

4.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Бәйрәкә
авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина

